

Мордовия Госсобрание рәисе Владимир Чибиркиннын депутатлар - барлык фракцияләр әгъзалары белән эшлекле кинәшмәсе регионыбызда сайлау кампаниясенә әзерләv темасына багышланган иде.       Быел бердәм тавыш бирv коне 20 сентябрьдә булачак. Республика халкына Мордовия Главасын, Россия Дәvләт Думасы һәм Мордовия Дәvләт Жыелышы - Госсобраниесе депутатларын, шулай ук Саранск депутатлар Советын һәм барлык дәрәжәдәге вәкиллекле органнарны сайларга туры киләчәк. Бу Идел буе федераль округы территориясендә ин зур сайлау кампаниясе булачак.
Безнен республикада беренче мәртәбә сайлаулар тугыз муниципаль округта узачак. Аларда авыл жирлекләренен вәкиллекле органнары тозелмәячәк; анда муниципаль округлар депутатлары советларына гына сайлаулар узачак.
«Сайлау процессынын vтә kvрен-мәлелеге һәм легитимлыгы, анда катнашучыларнын иминлеген тәэмин итv берсvзсез остенлек булып тора»,- дип ассызыклады Владимир Чибиркин.
Агымдагы этапта топ бурыч – сайлау участокларын әзерләv, алар очен бvлеп бирелгән биналарны һәм бvлмәләрне норматив хәлгә ки-терv, сайлау ко-миссияләре һәм kvзәтvчеләр эше очен тиешле шартлар тудыру. Мордовия Дәvләт Жыены рәисе депутатларга бу мәсьәләләрдә муниципалитет житәкчеләренә ярдәм kvрсәтергә кушты.
Очрашуда регионыбыз Сайлау комиссиясе рәисе (Председатель регионального Избиркома) Александр Косов һәм Мордовия хәрби комиссариаты вәкиле катнашты.
Александр Косов депутатларга булачак сайлау кампаниясе турында жентекләбрәк сойләде. Гражданнарга аларнын vзләренен сайлау хокукын гамәлгә ашыру момкинлеге турында кин мәгълvмат бирv планлаштырыла: сайлау участокларында vз-vзләрен тоту кагыйдәләре турында тулы мәгълvмат биреләчәк, диде.
Мордовия территориясендә электрон тавыш бирvне кулланмаска дигән карар кабул ителде.
Эшлекле кинәшмә кысаларында тагын бер моһим мәсьәлә тикшерелде, шунын очен депутатлар белән очрашуга Мордовия хәрби комиссариаты вәкиле чакырылган иде. Сvз парламент корпусынын махсус хәрби операция бурычларын хәл итvгә, контракт хезмәтенә керvче гражданнарга ярдәм kvрсәтv турында барды.

**Наилә НАСЫРОВА** әзерләде,
фото РМ Госсобраниесе
сайтыннан алынды